# Рөстәм Миңнеханов Татарстан Республикасы Дәүләт Советына еллык юллама белән мөрәҗәгать итте

21 сентябрь 2017 ел., пәнҗешәмбе

Бүген Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнехов Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз беренче кысаларында республиканың эчке һәм тышкы хәле турындагы еллык юллама белән мөрәҗәгать итте.

Чара Салих Сәйдәш исемендәге ЗДКЗда (Казан) узды.

Чарада Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Татарстан Республикасы Премьер-министры Алексей Песошин, Дәүләт Думасы депутатлары, Татарстан Республикасының чит илләрдәге һәм Россия төбәкләрендәге даими вәкилләре, муниципаль берәмлекләр башлыклары, сәнәгать предприятиеләр, банклар, югары уку йортлары вәкилләре, иҗат интеллигенциясе, җәмәгать оешмалары вәкилләре һәм башкалар катнаша.

«Хөрмәтле депутатлар, хөрмәтле ватандашлар!

Хөрмәтле Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары
һәм сессиядә катнашучылар!

Хөрмәтле татарстанлылар!

Татарстан Республикасы үзенең тотрыклы үсешен дәвам итә, күп кенә социаль-икътисадый күрсәткечләр буенча илдә алдынгылар сафында тора, тормыш өчен һәм бизнес белән шөгыльләнү өчен республикада уңай шартлар тәэмин ителә.

Соңгы дистә еллар эчендә без икътисадта нәтиҗәле базар моделен булдыруга ирештек, лаеклы социаль стандартлар һәм киң сәяси ирек булдыруны тәэмин иттек, кешеләрнең күркәм башлангычларын хуплау һәм аларны тормышка ашыру өчен шартлар тудырдык.

Шул ук вакытта глобальләшү нәтиҗәсендә килеп чыккан кыенлыкларның кискенләшүе, технологияләрнең һәм кешеләрнең өстенлекле ихтыяҗлары тиз үзгәрү базарларның яңадан бүленешенә һәм иҗтимагый үсешнең яңача корылуына китерә.

Без бу үзгәрешләрдә актив катнашырга, алдан күреп эш итәргә, республика мәнфәгатьләрендә һәм гражданнарыбызның тормыш сыйфатын яхшырту өчен эшчәнлегебездә яңа юнәлешләрне файдаланырга тиешбез.

Дөньядагы каршылыклы үзгәрешләр һәм төрле куркынычлар Россия Федерациясен төрле халыкларның уртак йорты буларак ныгытуда мөмкин булган барлык чараларны куллануны таләп итә.

Күпгасырлык тарихыбыз, татарлар, руслар һәм башка халыкларның рухи берләшүе аша без Россия дәүләтчелегенә аерылгысыз бәйләнгәнбез. Республикабызның, кайда яшәүләренә карамастан, барлык татарларның бәрәкәтле үсешен бары тик көчле Россия генә гарантияли алуын без бик ачык аңлыйбыз.

Татарстан бүген социаль-икътисадый һәм инфраструктура өлкәсенә инвестицияләр җәлеп итү буенча киң колачлы проектларны гамәлгә ашыра. Бездә дөнья күләмендәге спорт ярышлары, төрле форумнар уздырыла.

Республикабызның казанышларын федераль үзәк, һәм, беренче нәүбәттә, илкүләм лидерыбыз Владимир Владимирович Путинның ышанычы һәм саллы ярдәменнән башка күзаллавы мөмкин түгел.

Россия үзенең  көчле төбәкләре белән куәтле – безнең бөтен яшәешебез көннән-көн шуны дәлилли.

Шуңа бәйле рәвештә Россия Федерациясе Президентын сайлау  бездән көчебезне аеруча туплауны, берләшүне таләп итә. Үтә мөһим сайлау кампаниясе илебезгә гаять көчле сәяси, икътисадый һәм мәгълүмати басым ясау шартларында  узачак дип уйларга нигез бар.

Мондый хәвефле шартлар Россиянең цивилизацияле үсеш юлын сайлавына теләктәшлек күрсәтү, аның мәнфәгатьләрен эзлекле рәвештә яклау, Президентның ил куәтен арттыруга юнәлтелгән курсын хуплау максатында татарстанлыларга, җәмгыятьтәге алдынгы карашлы һәм фикерле кешеләргә өстәмә этәргеч бирәчәгенә шигем юк.

Чирек гасыр дәвамында безнең федераль үзәк белән багланышларыбыз вәкаләтләр бүлешү турындагы шартнамәләр нигезендә билгеләнде. Алар гаять мөһим тарихи роль уйнады, дәүләтчелекне ныгытуга һәм гамәлдәге Россия федерализмын камилләштерүгә ярдәм итте.

Бу шартнамәләрнең күп кенә нигезләмәләре Россия Федерациясе законнарына кертелде һәм төбәкләр белән үзара мөнәсәбәтләрдә аларга таянып эш итү табигый хәлгә әйләнде.

Илнең алдынгы субъектларыннан берсе буларак, Татарстан бүген  башлангычларны һәм проектларны гамәлгә ашырганда, демократик хокукый дәүләт – Россия Федерациясендәге киң мөмкинлекләрдән тулысынча файдалана.

Федераль үзәк белән республика  мөнәсәбәтләренең рәвешенә караганда, аларның эчтәлеге, уртак мәнфәгатьләрдә килеп туган мәсьәләләрне һәр ике якны канәгатьләндерерлек итеп хәл кылу мөмкинлеге хәзерге шартларда мөһимрәк булуын да әйтеп китәргә кирәк.

Хөрмәтле депутатлар!

Җәмгыятьнең хәзерге үсеш дәрәҗәсе өчен гражданнарның һәм аларның берләшмәләренең дәүләт идарәсе өлкәсендә карарлар кабул итү һәм аларны гамәлгә ашыру барышына йогынтысы арту хас.

Моңа электрон сервисларның һәм хезмәт күрсәтүләрнең бердәм платформасы ярдәм итәргә тиеш.

Гражданнар белән үзара элемтәләрнең, аларның башлангычларына ярдәм күрсәтүнең заманча механизмнарыннан киңрәк файдалану күздә тотыла.

Хакимият органнары эшчәнлегенең төп максатларын һәм күрсәткечләрен булдыру, шулай ук аларның үтәлешенә контрольлек итү ачыктан-ачык алып барылырга тиеш.

Парламентның сайлаучылар һәм иҗтимагый институтлар белән элемтәләрен ныгыту, депутатларның тормыш-көнкүрешнең үзәгендә, аеруча кыен хәлләр еш килеп туа торган урыннарда булуы бик мөһим.

Халык белән эшләгәндә, безгә муниципаль җирлекләрнең, шулай ук җирле иҗтимагый үзидарәнең  киң мөмкинлекләреннән файдаланырга кирәк.

Җәмәгать урыннарын булдыруда һәм әлеге мәйданчыкларда төрлечә актив эшчәнлек алып баруда гражданнарның катнашу рәвешләрен арттыру юнәлешендә эшләү шарт.

Гражданнар башлангычларына нигезләнгән проектларда халыктан кергән  1 сумга республикадан 4 сум бүлеп бирүгә корылган инструменттан файдалану уңай нәтиҗә бирә.

Гражданнарны җирлек әһәмиятендәге мәсьәләләрне шушындый юл белән хәл итүгә тарту эше Арча, Балтач, Кукмара, Мөслим районнарында яхшы оештырылган.

Әйтергә кирәк, программаны гамәлгә ашыра башлаганнан алып бюджет хисабына финанслау гомумән алганда 2 миллиард сумнан артып китте.

Шушы акчага яңа юллар, күперләр, балалар һәм спорт мәйданчыклары, халыкка кирәкле башка объектлар төзелде.

Без бу эшне дәвам итәчәкбез.

Республика хөкүмәтенә һәм муниципаль берәмлекләр башлыкларына дәүләт хезмәтләрен үтәүне ешрак коммерциячел булмаган оешмаларга тапшырырга, аларның җәмгыять өчен файдалы хезмәт күрсәтүче дигән статус алырга омтылышын хупларга, шул исәптән коммерциячел булмаган оешмаларның ресурс үзәкләрен төзүне дә кертеп, аларга ярдәм итү рәвешләрен камилләштерергә кирәк.

Әлеге мәсьәләләрнең Социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмаларның IV республика форумында карап тикшерелүе отышлы булачак.

Татарстанлыларның республика тормышында катнашуы үсешебезгә этәргеч бирүче бәрәкәтле көчкә әверелергә тиеш. Бу эштә массакүләм мәгълүмат чараларына һәм Интернет ресурсларга зуррак роль бирү кирәк.

Технологик алгарыш кешеләрнең гадәтләренә, аралашу культурасына үзгәрешләр кертә. Мобиль җайланмалар мәгълүматтан файдалануның һәм аның таралышының төп чыганагы булу белән берргәттән, социаль активлык чарасына да әверелделәр.

Массакүләм мәгълүмат чаралары эшчәнлегендә төп игътибарны контентның сыйфатына, аның таралыш ысулларына һәм җәһәтлегенә юнәлтергә кирәк.

Кешеләрнең мәнфәгатьләре туктаусыз үзгәреш кичерүен һәм дөнья трендларының көчәюен исәпкә алу зарур.

Мәгълүмат тарату каналларының үзгәрүе һәм күптөрлелеге «Татмедиа» республика агентлыгы алдына мәгълүмат мәйданын булдыруда үзенең нинди роль уйнарга тиешлеген кабаттан карап тикшерү бурычын куя. Бу мәйданның күпкырлы, иҗади эшчәнлегебезне чагылдырып кына калмыйча, халык белән бәйләнеш урнаштыруда нәтиҗәле чара булуы да таләп ителә.

Хөрмәтле депутатлар!

Республикада милләтара һәм динара элемтәләрнең, этномәдәни үсешнең югары дәрәҗәдә булуы Татарстан халыкларының өченче съездында һәм Бөтендөнья татар конгрессының алтынчы съездында ачык чагылыш тапты.

Хакимият органнарына Татарстан халыклары ассамблеясе һәм Бөтендөнья татар конгрессы белән бергәләп әлеге абруйлы форумнар тәкъдим иткән барлык чаралар комплексын җентекләп эшләү зарур.

Алга таба да дәүләтнең милли сәясәтен гамәлгә ашыру программалары эчтәлеген һәм этник-конфессиональ өлкәдә мониторинглау эшләрен алып баруны камилләштерергә кирәк.

Телгә кагылышлы сәясәт мәсьәләләре аеруча зур игътибар бирүне таләп итә.

Дәүләт телләрен һәм туган телләрне өйрәнүгә өстенлек бирүне саклап калган хәлдә, республиканың Мәгариф һәм фән министрлыгына рус телен өйрәнүнең һәм белүнең югары дәрәҗәсен тәэмин итүгә игътибарны арттырырга кирәк.

Аерым алганда, республикада игълан ителгән Лев Николаевич Толстой елы кысаларында алып барылган эш моңа ярдәм итәчәк.

Шуның белән бергә, Татарстан Республикасының дәүләт теле буларак, татар телен укыту методикасын, шулай ук укытучылар әзерләүне һәм аларга яңадан әзерлек бирүне, шул исәптән кабат төзелә торган Милли педагогия институты базасында да бу эшне камилләштерү зарур.

Телләрне өйрәткәндә, башлыча коммуникатив күнекмәләрне үстерү таләп ителә.

Бу бурычлар республиканың Мәгариф һәм фән министрлыгы алдында бер генә тапкыр куелмады инде. Әмма башкарыла торган эшнең нәтиҗәләлеге һаман да югары түгел һәм гражданнар нигезле рәвештә моңа ризасызлык белдерә.

Җаваплылык үзәге буларак, министрлыкка тиешле нәтиҗәләр ясарга һәм кирәкле чаралар күрергә кирәк.

Республикабызның гына түгел, гомумән, бөтен Россиянең кадерле тарихи ядкаре – Казан Мәрьям Ана иконасы Соборын торгызу, шулай ук Болгар ислам академиясе биналары комплексын төзү бөтен халык катнашкан уртак эш, җәмгыятьтәге татулык чагылыш тапкан гамәл булды.

Академия, **һичшиксез,** алдынгы фәнни һәм рухи үзәккә әйләнеп, традицион исламны ныгытуга зур өлеш кертергә тиеш.

Без киләчәктә дә традицион конфессияләрнең радикальлеккә һәм катгый кире кагуның теләсә-кайсы рәвешенә каршы көрәшүенә, җәмгыятебездә барган рухи-әхлакый үсештә үз рольләрен арттыруга юнәлтелгән тырышлыгына эзлекле төстә ярдәм күрсәтәчәкбез.

Төрле этник төркемнәр һәм диннәр вәкилләренең үзара файдалы багланышлары һәм хезмәттәшлеге, республикадагы милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне ныгыту, илебездән читтә яшәүче ватандашларга булышлык күрсәтү – барлык дәүләт һәм муниципаль хакимият органнарының мөһим бурычы.

Тарихи-мәдәни мирасны саклап калу эше республикада һәрчак игътибар үзәгендә. Матди булмаган мәдәни мирас турында закон кабул ителде.

Успение соборының, Свияжск утрау-шәһәрчеге монастыреның ЮНЕСКОның бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелүе илебезнең зур казанышы булды.

Бу исә галимнәрнең, археологларның, реставраторлар һәм төзүчеләрнең, хезмәт коллективларының һәм инде, әлбәттә, Минтимер Шәрип улы Шәймиев җитәкләгән «Яңарыш» фондының күпьеллык тырыш хезмәтенең закончалыклы нәтиҗәсе булып тора.

Россиянең Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелгән егерме тугыз объектыннан өчесе безнең республикабыз территориясендә урнашкан.

ЮНЕСКОның таләпләре артуны исәпкә алып, республиканың Дәүләт Советына әлеге объектларга мөнәсәбәтле рәвештә аларның саклануын, бөтенлеген һәм борынгылыгын законнар нигезендә тәэмин итү чараларын карау зарур.

Тупланган тәҗрибәгә таянып, тарихи-мәдәни мирас объектларында археология-тикшеренү һәм торгызу эшләрен, шулай ук төрле халыкара проектларда катнашуны дәвам итәргә кирәк.

ТАССР оешуга 100 ел тулуга багышланган чаралар, һичшиксез, татарстанлыларның бердәмлеге, Россия Федерациясе халыкларының татулыгы тагын да ныгуга ярдәм итәчәк.

Алар арасында республика районнарында социаль-мәдәни өлкәдә яңа объектлар ачылу, җәмәгать урыннары булдыру кебек эшләр бар.

Республика хөкүмәтенә башкалабызда юбилей белән бәйләнешле объектларны – Милли китапханәне, универсаль зур концерт залын төзү проектларын гамәлгә ашыруны тизләтергә кирәк.

Бу истәлекле дата алдыннан Архив эше буенча дәүләт комитетына зур эш башкарырга туры киләчәк, өстәвенә бу зур юбилей көннәрендә архив хезмәтенә дә йөз ел тулачак.

Архив өлкәсен югары технологияле, аннан барлык гражданнар да файдалана алырлык итү гаять мөһим.

Республиканың зур мирасы, вакыйгаларга бай эшлекле, мәдәни һәм спорт тормышы Татарстанның көннән-көн танылу баруына ярдәм итә.

Ел саен бездә утыздан артык киң колачлы халыкара чаралар һәм форумнар уздырыла.

Киләсе елда Казанда Футбол буенча дөнья чемпионаты матчлары, 2019 елда исә WorldSkills дөнья беренчелеге, 2022 елда Кыска арага йөзү буенча дөнья чемпионаты булачак. Безнең бурыч – аларны иң югары дәрәҗәдә уздыру.

Туристлык тармагы, казанышларыбызны популярлаштыруның иң мөһим бурычларын хәл итә килеп, икътисад үсешенең мөһим факторына әверелә бара.

Узган елда республикада өч миллион тирәсе кеше булып китте. Киләчәктә дә кунакчыллык инфраструктурасын камилләштерү, туристлыкның яңа төрләрен үстерү мөһим.

Күпмилләтле халкыбызның ментальлеге, аның рухы, үзенчәлекле традицияләре мәдәнияттә чагылыш таба. Аның киң мәгънәсен ачу гаять мөһим. Мәдәният ул – матди, рухи мирасны саклап калудан тыш, кешеләрне берләштерүче рухи хәзинәләр, яңа мәдәни продуктлар булдыру.

Мәдәният хәзерге үсеш дәрәҗәсендә мәгариф системасы, туристлык, спорт өлкәсе, архив һәм китапханә эше белән тыгыз берлектә булырга тиеш.

Мәдәниятнең үткәнгә генә түгел, киләчәккә дә карап эш йөртүе, замана таләпләренә җавап бирүе мөһим.

Бу аеруча яшьләргә кагыла, ә алар исә үткәннәр белән чагыштыруны кабул итә алмый һәм яңа йогынтыларга җиңел бирелә, ышаныч белдерүгә һәм социаль гаделлеккә аеруча сизгер, шәхес буларак ачылу мөмкинлеген югары бәяли һәм дөньядагы иң яхшы казанышларга йөз тота.

Гражданлык, ватанпәрвәрлек хисе тәрбияләүнең һәм традицион рухи хәзинәләрне маяк итүнең әһәмиятен таныган хәлдә, егет-кызларның башлангыч һөнәри күнекмәләр алуда, проектлар төзү эшчәнлегендә, перспективалы һөнәрләр үзләштерүдә кече яшьтән катнашуының нәтиҗәле моделен төзү хакимият органнарының шулай ук өстенлекле бурычына әверелә.

Тирәлек үзе үк уңышка, эшлеклелеккә, уникаль белемнәр һәм күнекмәләр үзләштерүгә, үсешкә юнәлгәнлек формалаштырырга, шушыларның модага керүенә ярдәм итәргә тиеш.

Талантлы, иҗади яшьләр һәм аларның берләшмәләре белән эшләүгә аеруча игътибар бирергә кирәк. Креатив индустрияләр, ресурс үзәкләре булдыру мөһим.

Гадәттә бирегә тормыш сыйфатын яхшыртуга юнәлтелгән кызыклы, үзенчәлекле фикерләре булган кешеләр килә.

Республиканың зур шәһәрләрендә мәйданчыклар булдыру тәҗрибәсен муниципалитетларда да файдаланырга кирәк. Югары уку йортларыбыз һәм башка уку учреждениеләре бу эшне төп башкаручылар булырга тиеш.

Билгеләп үтәм, яшьләр мәктәптән үк үз киләчәген республика белән бәйләүне күздә тотарга, безнең алар үсешендә кызыксынган булуыбызны, тормышлары һәм эшләре өчен лаеклы шартлар тудырырга тырышуыбызны ачык тоярга тиешләр.

Хөрмәтле депутатлар!

Халыкара мөнәсәбәтләрнең кискенләшүе һәм төрле хәвефләр арту шартларында Татарстан өчен халыкара һәм төбәкара элемтәләр аеруча зур әһәмият ала.

145 ил партнерлары белән үзара файдалы элемтәләрне үстерә киләбез.

Дөньякүләм югары технологияле җитештерү өлкәсендәге лидерлар хезмәттәшлек һәм инвестицияләү өчен Татарстанны сайлады.

Россиянең һәм чит илләрнең хөкүмәтара комиссияләре үзара хезмәттәшлекне ныгытуның үтемле чарасына әйләнде. Аларның утырышлары Казанда хәзер тагын да ешрак уздырыла.

Россия Федерациясенең ислам дәүләтләре белән якынаюы буенча илебез Президенты куйган бурычлар «Россия – ислам дөньясы» стратегик караш төркеме кысаларында уңышлы хәл ителә.

Алга таба да ислам илләре партнерлары, Ислам хезмәттәшлеге оешмасы, Ислам үсеш банкы һәм башка халыкара институтлар белән хезмәттәшлек рәвешләрен тагын да арттыра барырга, шулай ук республика территориясендә ислам финанс механизмнарын, шул исәптән KazanSummit халыкара форумы кысаларында да, үстерүне дәвам итәргә кирәк.

Россиянең Чит илләр эшләре министрлыгы белән тыгыз элемтәдә торып, Татарстан ватандашлар белән хезмәттәшлек итә, бу исә республиканың тышкы элемтәләрендә иң мөһим юнәлешләрнең берсе булып тора.

Хөрмәтле хезмәттәшләр!

Дөньяны дүртенче сәнәгать революциясе били бара. Без – мөһим һәм кызыклы технологик үзгәртеп корулар шаһитлары.

Блокчейн, БигДэйт, ясалма интеллект – болар хәзер хыял түгел, чынбарлык инде.

Бүген үз алдыбызга иң әһәмиятле – «Без бу үзгәрешләргә әзерме соң?» дигән сорауны куярга тиеш.

Без җәмгыятьтәге икътисадый һәм җитештерү моделенең эволюцион үсешендә цифрлы икътисад дип аталган чираттагы стадиягә аяк бастык.

Эзлекле цифрлаштыру хезмәт җитештерүчәнлеген һәм икътисадның конкурентлык сәләтен арттырырга, традицион тармакларның мөмкинлекләрен ачарга һәм яңа сегментлар булдырырга мөмкинлек бирәчәк.

Шул ук вакытта яңа технологияләр кертү кайбер һөнәрләрнең, компанияләрнең, хәтта ки тармакларның юкка чыгуына китерә.

Без үзгәртеп корулар агымына кушылырга һәм аларны республика мәнфәгатьләрендә файдаланырга тиешбез.

Гомумән алганда, безгә ерак киләчәккә карап эш итәргә, алдагыны истә тотып уй йөртергә кирәк.

Бүгеннән үк инде 5, 10, 20, хәтта 30 елдан үз көченә керәчәк законнар һәм механизмнар турында фикер алышырга һәм аларны кабул итәргә кирәк.

Республикада гамәлгә ашырыла торган чаралар комплексы безнең Үсеш стратегиясе кысаларында икътисадта уңай динамика булдырырга мөмкинлек бирә.

Быел тулай төбәк продукты үсеше 4 процент тирәсе тәшкил итте.

Тышкы санкцияләрнең озак вакыт дәвам итүе шартларында киләчәк үсеш өчен эчке резервларны активлаштыру гаять мөһим.

Хәзерге этапта икътисад үсешенең нигезен нефть һәм газ комплексы тәшкил итә.

Нефть сәнәгате каршында торган иң зур кыенлык – запаслар структурасы, ресурслар базасы сыйфатының начараюы.

Илдә «җиңел нефть» чоры тәмамланды. Татарстанда нефть чыгару эше фән казанышларын күбрәк файдалана торган, интеллектуаль процесска әйләнә бара.

Шул ук вакытта илебез нефть сәнәгатенең аларны җир астыннан чыгару кыенлыклар тудыра торган запасларны үзләштерүдә чит ил технологияләренә бәйлелеге саклана. Биредә технологик ачышлар таләп ителә.

«Татнефть» бүгенге көндә югары технологияле сәнәгать ысуллары белән нефть чыгаруга күчте. Киләсе этапта Россиянең нефть сәнәгатендә инновацияләр эшләү һәм аларны файдалануга кертү буенча технологияләр өлкәсендәге берсүзсез лидерлыкка чыгу бурычы тора.

Нефть эшкәртү сәнәгатен үстерү өлкәсендә 2018 елда республикада эшкәртелә торган нефть күләмен, тирәнтен эшкәртүне 98 процентка җиткереп, 23 миллион тоннага кадәр арттыру бурычы актуальлеген югалтмый.

Нефть эшкәртү предприятиеләре республиканың нефть химиясе производстволары өчен төп чимал җитештерүчеләр булып тора. Нефть эшкәртү һәм нефть химиясе тармакларының тыгыз бәйләнешен алга таба да үстерә бару зарур.

Республиканың нефть химиясе сәнәгатендә мономерлардан полимерлар эшләү производстволары булган «Этилен-600» этилен комплексы төзелеше төп проект булып тора.

2021 елга яңа производстволарны эшләтеп җибәрү Түбән Кама нефтехимда пластиклар һәм синтетик каучуклар җитештерүне икеләтә арттырырга мөмкинлек бирәчәк.

Гомумән алганда, ТАИФ компанияләр төркеме тарафыннан проектлар гамәлгә ашырылганнан соң Татарстан илдә полимерлар җитештерүчеләрнең иң күренеклесе булачак.

Республикада полимер продукцияне эшкәртү кластерын үстерү бурычы актуаль булып кала.

Республиканың машина төзү комплексында КАМАЗда кабиналар каркасы заводы төзелеше тәмамлану алдында торуын (2018 елда), бер рәттәге 6 цилиндрлы яңа двигательләр производствосын эшләтеп җибәрүне (2018 елда), КАМАЗ автомобильләренең магистраль төрдәге К5 буынының принципиаль яңа моделен базарга чыгаруны билгеләп китү урынлы булыр.

Газ-мотор транспорты базарын үстерү проекты кысаларында «Газпром газ-мотор ягулыгы» компаниясе белән хезмәттәшлек итүне, шулай ук электр транспортын һәм пилотсыз автомобильләр җитештерүне, шул исәптән Шатл проекты буенча да, үстерү эшен дәвам итәргә кирәк.

Бу яктан без дөрес юнәлештә эшлибез һәм Милли технологик инициативаның федераль повесткасына тулысынча туры киләбез.

Моннан тыш, машина төзү тармагында Казан вертолет заводында Ансат һәм Ми-38 вертолетларын, Горбунов исемендәге Казан авиация заводы базасында модернизацияләнгән ТУ-160 самолетын сериялэп җитештерү, шулай ук Зеленодольскиның Горький исемендәге заводында кораблар җитештерүне һәм экспортлауны арттыру өстенлекле бурыч булып тора.

Җитештерү өлкәсенең үсешендә иң төп бурычларның берсе – югары технологияле ике тармак – граждан һәм оборона тармаклары билгеләнешендәге продукция җитештерүдә Оборона-сәнәгать комплексы мөмкинлекләреннән файдалану.

Энергетика өлкәсендә республикада электр белән тәэмин итүнең ышанычлылыгын арттыруга юнәлтелгән проектлар тормышка ашырыла. Казанның 3 нче Җылылык-электр үзәгендә Россиядә иң куәтле газ-турбина җайланмасы эшли башлады, Щелоков – Үзәк югары вольтлы линиясен төзү эше дәвам итә.

Киләсе елда Казанның 1 нче Җылылык-электр үзәгендә пар-газ җайланмасы төзү эшен тәмамларга, шулай ук Зәй дәүләт район электр станциясен модернизацияләүгә тотынырга тиешбез.

Шуның белән бергә, алга таба эзлекле төстә энергиянең альтернатив чыганакларыннан файдалануга күчү зарур.

Бүгенге көндә республикада билгеләнгән күләме 100 МВт суммар көчәнешле җил парклары төзү проектын гамәлгә ашыру буенча эш алып барыла.

Кама инновация кластеры предприятиеләре үзләре билгеләгән инвестиция проектларын уңышлы гамәлгә ашыра килеп, уңай үсеш динамикасы күрсәтә.

Моңа Иннокамда төзелгән «Алабуга» махсус-икътисадый зонасы, Чаллы шәһәрендәге алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе һәм Түбән Кама шәһәрендә булдырылачак шундый ук территория кебек ярдәмче инструментлар булышлык итә.

Әмма инфраструктура проектлары кластеры планлаштырылган темплардан күпкә калыша.

Министрлык җитәкчеләренә төп игътибарны тармак чараларын һәм концепцияләрне тиешле федераль программаларга кертүгә юнәлтергә кирәк.

Республикага чит ил инвестицияләре, алдынгы технологияләр җәлеп итүдә «Алабуга» махсус икътисадый зонасы зур роль уйный.

Әлеге эштә киләсе баскыч – зона кластерларын үстерү, нефть химиясе һәм нефть эшкәртү юнәлешендәге «Алабуга-2» индустриаль паркын булдыру.

Алабуганың зона белән идарә итү һәм резидентларны кадрлар белән тәэмин итүдәге уңай тәҗрибәсен сәнәгать парклары, шулай ук Түбән Кама, Чистай һәм Зеленодольскида төзелүче алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе идарәче командалары актив файдаланырга  тиеш.

Республикабызда социаль-икътисадый алгарышлы үсеш территориясе булдыруга федераль үзәк тарафыннан белдерелгән ышаныч безгә, үз чиратыбызда, аны резидентлар белән тәэмин итү җаваплылыгы өсти. Бу Моношәһәрләр башлыкларының һәм Инвестицион үсеш агентлыгының турыдан-туры бурычы булып тора.

Моннан тыш, киләсе елдан Ерак Көнчыгышның алгарышлы үсеш территорияләренә тәңгәл территорияләр төзү мөмкинлеге дә барлыкка киләчәк.

Район башлыкларына мөрәҗәгать итеп, Икътисад министрлыгы белән берлектә алгарышлы үсештәге яңа территорияләрне, шул исәптән муниципальара хезмәттәшлек һәм кооперация нигезендә дә, формалаштыру буенча тәкъдимнәр әзерләүләрен сорыйм.

Хәзерге заман шуны таләп итә: территорияләрне үзара нәтиҗәле үстерү һәм хезмәт ресурсларын бер-берсендә файдалану максатларында муниципалитетлар үзара сөйләшүләр алып барырга һәм билгеле бер килешүләргә ирешергә тиеш.

Илебез ИТ-секторының перспективалы үсеш зонасы булып торучы «Иннополис» махсус икътисадый зонасын һәм шул ук исемдәге шәһәрне үстерү эше дәвам итә.

Биредә цифрлы икътисад үсешенә бәйле тикшеренүләр һәм хезмәтләр тупланырга тиеш.

ИТ-шәһәрнең төп өстенлеге – Иннополис Университеты. Киләчәктә студентлар санын 5 меңгә җиткерү планлаштырыла.

Бөтен дөнья студентларына Интернет аша әлеге югары уку йорты программалары буенча белем алу мөмкинлеге тудырырга кирәк. Бу исә, үз чиратында, әлеге амбицияле проектка игътибарның артуына һәм тагын да күбрәк студентлар җәлеп итүгә этәргеч бирәчәк.

Федераль проект буларак, Иннополис тулаем илебез мәнфәгатьләрендә хезмәт итәргә һәм экспорт юнәлешен үстерергә тиеш.

Әлеге бурычлар махсус икътисадый зонаның Лаеш районындагы икенче мәйданчыгына да кагыла. Аны алга таба да үстерү буенча эшне активлаштырырга кирәк.

Республикада кече һәм урта эшкуарлыкка булышлык йөзеннән заманча инфраструктура булдырылды.

«Мастер» Кама индустриаль паркы, «Химград» технополисы, «ИТ-парк» һәм «Идея» технопаркы уңышлы эшләп килә.

Республикада бизнесны үстерү инфраструктурасы булдыру эше үзенең уңай нәтиҗәләрен бирә. Сәнәгать җитештерүенең гомуми күләмендә аларның резидентлары өлеше инде 9 процентан артып китә. Безгә әле үсеш өчен мәйдан киң.

Сүз, әлбәттә, муниципаль сәнәгать мәйданчыклары эшенең нәтиҗәлелеген арттыру турында бара. Бу аеруча Мамадыш районындагы «Нократ», Чаллы

шәһәрендәге «Үсеш» һәм Яңа Чишмә районындагы сәнәгать мәйданчыклары эшенә кагыла.

Республика әлеге сәнәгать мәйданчыкларын төзүгә бик күп акча бүлеп бирә. Һәм безнең алардан билгеле бер нәтиҗә таләп итәргә тулы хакыбыз бар.

Сәнәгать мәйданчыклары төзү һәм аларга идарә итү, аларның сыйфатлы эшләвен булдыру һәм резидентлар җәлеп итү – турыдан-туры район башлыкларының бурычы ул! Әлеге мәйданчыклар киләчәктә муниципалитетларның төп керем чыганакларының берсе булачак һәм яңа эш урыннары булдыруны тәэмин итәчәк.

Түбән Кама һәм Әлмәт шәһәрләрендә уңай мисаллар бар. Анда зур сәнәгать предприятиеләре булуга да карамастан, төп компанияләргә бәйсез рәвештә, кече бизнесны үстерү эше актив алып барыла.

Һәр муниципалитет территориясендә бизнес өчен конкурентлык мохите тудыру һәм аны стимуллаштыру мөһим.

Мәнфәгатьләр каршылыклары килеп чыгу һәм конкурентлыкның булмавы җирле бизнесның үсешенә тоткарлык ясый һәм, нәтиҗәдә, ул бөтенләй юкка чыга.

Без эшкуарларга үз бизнесын башлап җибәрү һәм үстерү, Татарстан икътисадына табыш китерә торган инвестицияләр җәлеп итү, килеп туган кыенлыкларны тиз арада һәм нәтиҗәле хәл итү өчен тиешле шартлар тудырырга тиеш.

Әлеге максатларда республикада Эшкуарлык фабрикасы, Бизнес-класс кебек уку-укыту программалары һәм башка проектлар гамәлгә ашырыла.

Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү буенча федераль корпорация белән берлектә республикада Төбәк лизинг компаниясе (устав капиталы – 2 миллиард сум) оештыру җирле товар җитештерүчеләр өчен зур ярдәм булып тора.

Нәтиҗәдә, республиканың кече һәм урта бизнесы вәкилләренә лизингка түбән бәядән җиһазлар сатып алудан тыш, зур компанияләр оештырган югары технологияле сатып алу процессларында катнашу мөмкинлеге бирелә.

Моның белән беррәттән, бизнеска тагын да зуррак мөмкинлекләр тудырырга һәм административ киртәләрне киметергә кирәк.

Тагын бер кат басым ясап әйтәм, контроль-күзәтчелек органнарының төп бурычы – бизнеска штрафлар салу түгел, ә бәлки эшкуарлар белән бергәлектә, алдан тикшерүләр уздыру, кисәтүләр һәм искәртүләр белдерү кебек механизмнарны тулы күләмдә файдаланып, закон бозу очракларын бетерү.

Конкурентлыкка сәләтен арттыру өчен җирле товар җитештерүчеләргә тышкы базарларга чыгу мөһим.

Товар белән тәэмин итүнең глобаль чылбырын үзгәртүгә юнәлтелгән санкцияләр экспорт мөмкинлекләрен киметә. Әлеге шартларда гамәлдә булган экспорт базарларын саклап калу һәм яңаларын эзләү бик мөһим.

Бу, шул исәптән, хакимият органнарының да бурычы булып тора. Хөкүмәткә мөрәҗәгать итеп, тиз арада экспортны үстерү стратегиясен эшләп бетерүне сорыйм.

Финанс базарлары эшенә аерым тукталасым килә. Банк секторында килеп туган вазгыять барыбыз өчен дә зур сабак булды. Һәркем үзе өчен тиешле нәтиҗәләр ясарга тиеш.

Әлеге вазгыять нәтиҗәсендә туган киеренкелекне хәл итүдә тиз арада консультацияләр бирү эшен башлап җибәрү һәм зыян күрүчеләргә яңа финанс инструментлары ярдәмендә булышлык итү зур роль уйнады.

Моннан тыш, Татарстан җитәкчеләре карары белән Республика ярдәм фонды гамәлгә куелды, аның эшчәнлеге нәтиҗәсендә банклар клиентларының күпчелеге проблемаларын хәл итәргә мөмкин булачак.

Хөкүмәтебезгә Фонд белән берлектә тиз арада зыян күрүчеләргә ярдәм итү механизмнарын эшләү кирәк.

Тулаем алганда, әлеге кризисның тискәре нәтиҗәләрен хәл итәргә һәм башка мондый күңелсез күренешләрне булдырмаска тырышырга кирәк.

Банклар үз эшчәнлеген туктату бизнес вәкилләренә генә зыян салу белән чикләнмәде. Әлеге хәл килеп тугач, халыкның заманча финанс-кредит системасы белән эшләүдә тиешле күнекмәләре булмау да ачыкланды.

Финанс оешмалары хисапларына аудит уздыруның сыйфаты мәсьәләсенә дә тиешле игътибар бирелергә тиеш.

Алга таба нәтиҗәсез карарлар кабул итүгә китерүче төгәлсезлекләргә юл куймау мөһим.

Хөкүмәттән Икътисадый совет кысаларында әлеге мәсьәләләрне тагын бер кат тикшерүне сорыйм.

Хөрмәтле хезмәттәшләр!

Сәнәгать инфраструктурасын үстерү барышында җәмәгать урыннары санын арттыру да зарур.

Территорияләрне үстерүгә архитекторлар, шәһәр төзүчеләре, инвесторлар һәм гражданнарның бердәм фикерен исәпкә алып, комплекслы якын килүне тәэмин итү гаять мөһим.

Җәмәгать урыннарын төзекләндерү программасы буенча 189 объект – парклар, скверлар, бульварлар төзелде һәм яр буйлары төзекләндерелде.

Әлеге эш быел да, республикада игълан ителгән Экология һәм җәмәгать урыннары елында да дәвам иттерелде. Бу – тагын 73 объект.

Уртак эшебезгә Татарстан предприятиеләре, аеруча Татнефть, ТАИФ компанияләр төркемнәре зур өлеш кертте.

Шунысын билгеләп китәм, безнең республикадагы программалар тәҗрибәсе федераль дәрәҗәдәге «Уңайлы шәһәр тирәлеген үстерү» өстенлекле проектына нигез итеп алынды, ә аларны гамәлгә ашыруга халыкны тарту Россиянең 12 мең муниципалитеты өчен мәҗбүригә әйләнде.

Быел без ишегалды территорияләрен һәм муниципалитетларның квартал эчендәге юлларын капиталь төзекләндерүгә төп игътибар бирдек.

Әлеге максатларга бюджеттан 2 миллиард сум акча бүлеп бирелде.

Моннан тыш, Экология елы кысаларында республикада 1200 чүплек юкка чыгарылды, 10 мең км озынлыкта яр буе полосасы һәм меңнәрчә су объектлары чистартылды, 4 мең гектар мәйданда 20 миллион агач үсентесе утыртылды, табигатьне саклау буенча төрле чараларда һәм акцияләрдә миллионнан артык татарстанлы катнашты.

Безнең бурыч – икътисадны үстерү һәм әйләнә-тирә мохитне саклау арасындагы тигезлекне югалтмау. Экология өлкәсендәге зур җаваплылык икътисадның реаль секторлары предприятиеләренә төшә.

Республиканы «яшел» икътисад принциплары нигезендә үстерү өчен Казан шәһәрендә коммуналь каты калдыкларны термик эшкәртү буенча завод төзү планлаштырыла.

Бу исә Казан шәһәре янындагы әһәмиятле җир кишәрлекләрен хуҗалык әйләнешеннән алу проблемасын хәл итү, әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтыны күп тапкырларга киметү, Швейцария, Германия, Голландия һәм Япония кебек илләрдәгечә коммуналь каты калдыкларны җиргә күммичә, тулысынча эшкәртү мөмкинлеге бирә.

Тулаем алганда, «яшел» икътисад теория булып кына калмыйча, көндәлек кулланылыштагы көнкүреш күнекмәләренә әйләнергә тиеш.

Аеруча зур игътибарны экологик тәрбия мәсьәләсенә бирү зарур.

Татарстанда тормыш сыйфатын яхшыртуга юнәлтелгән республика программаларын гамәлгә ашыру дәвам итә.

Бүгенге көндә аларның саны 37гә җитте. Әлеге максатларда республика бюджетыннан быел 16 миллиард сум акча бүлеп бирелде.

Программада – 2 911 объект. Шул исәптән, 11 яңа мәктәп, 9 балалар бакчасы, 42 фельдшер-акушерлык пункты, 6 табиблык амбулаториясе; меңгә якын күпфатирлы йорт, 106 сәламәтлек саклау объекты, 146 мәгариф учреждениесе капиталь төзекләндереләчәк; 260 км суүткәргеч төзелде, 44 скважина борауланды һәм 38 су басымын көйләү башнясы куелды.

Моннан тыш, 10 мең гаиләгә социаль ипотека программасы буенча фатир ачкычлары тапшырылачак.

Бу елда бакчачылык ширкәтләрен инфраструктура ягыннан үстерү, авыл кибетләре төзү, шулай ук поликлиникаларны һәм муниципаль архивларны капиталь төзекләндерү буенча яңа республика программалары эшли башлады.

Төзелешнең сыйфатын яхшырту, яңа технологияләрне кулланышка кертү буенча эшне дәвам итәргә, әлеге тармактагы конкурентлык мохитенә ярдәм күрсәтергә кирәк.

Без төзелештә өлешле катнашудан зыян күрүчеләр проблемаларын хәл итү буенча эшне актив рәвештә дәвам итәбез. Чараларның тулы бер комплексы үткәрелә.

Нәтиҗәдә, быел 275 кеше өчен 2 йорт тапшырылды, 12 объектта төзелеш эшләре алып барыла. Шулардан, ел ахырына 938 кеше өчен кимендә 6 йорт куллануга тапшырылачак.

Моннан тыш, без төзелештә өлешле катнашучылар проблемасын хәл итүне дәвам итү максатларында инвестиция проекты өчен республикабыз башкаласында 17 га мәйданда җир кишәрлеге бүлеп бирү турында карар кабул иттек.

Казан һәм Чаллы шәһәрләре башлыкларына Хөкүмәт ярдәме белән проблемалы өлешле төзелеш объектлары буенча эшне активлаштырырга кирәк.

Шул ук вакытта бары тик республика ярдәмен генә көтеп утырырга ярамый.

Торак төзелешендәге мәсьәләләрне вакытында хәл итүнең төрле формаларын һәм инструментларын табу зарур.

Соңгы елларда торак-коммуналь комплексына тиешле күләмдә акча бүлеп бирелә. Без гамәлдәге капиталь төзекләндерү программасы кысаларында күпфатирлы торак фондының торышын күпкә яхшыртуга ирештек.

Әмма моның белән генә республика халкының мөрәҗәгатьләре саны кимеми. Шикаятьләрнең күпчелеге Идарәче компанияләр эшчәнлегенә бәйле. Аларда күрсәтелгән хезмәтләрнең сыйфатына, түләүләрнең тиешле дәрәҗәдә аңлаешлы булмавына кагылышлы мәсьәләләр күтәрелә.

Уздырылган барлык тикшерүләр чыгымнарның нәтиҗәсез сарыф ителүен генә түгел, ә бәлки максатчан тотылмавын да дәлилли. Фатир өчен түләү документларында бик еш хаталар була, исәп-хисап счетларына нигезсез рәвештә өстәмә хезмәтләр кертелә. Болар барысы да халыкта тискәре мөнәсәбәт тудыра.

Район башлыкларына ай саен гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ ясарга һәм идарәче компанияләр эшенә бәя бирергә кирәк.

Тагын бер кат басым ясап әйтәм, торак-коммуналь хуҗалык өлкәсе мәсьәләләре муниципалитетлар җитәкчеләренең даими контролендә булырга тиеш. Әлеге тармактагы барлык тикшерүләрнең йомгаклары баланс комиссияләрендә җентекле анализланырга һәм тиешле идарәчел, ә кирәк булса, кадрларга кагылышлы карарлар да кабул итү өчен нигез булырга тиеш.

«Татэнергосбыт» составында бердәм республика исәп-хисап үзәге булдыру эшен тизләтергә кирәк. Берничә муниципалитетта пилот проектлар бар инде.

Әлеге системада кулланылучы оештыру чаралары һәм технологик чаралар торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүләр исәпләгәндә ачыклыкны тәэмин итүгә һәм, нәтиҗә буларак, коррупция күренешләрен булдырмауга ярдәм итә.

Территорияләрнең үзара бәйләнешен арттыруга юнәлтелгән эшне дәвам итү зарур.

Шул ук вакытта киләчәктә төзеләчәк транспорт челтәрләре республикада инде гамәлдә булган һәм төзелүче логистика үзәкләре аша узарга тиеш.

Йөк ташуларны координацияләү эше белән шөгыльләнүче бердәм диспетчерлык үзәге яисә операторы булдыру зарурлыгы килеп туды.

Хөкүмәттән әлеге мәсьәләгә кагылышлы эш уздыруны сорыйм.

Республикабыз территориясендә, торак пунктларда да, үзәк автомобиль юллары янында да, кәрәзле телефон элемтә челтәре начар эшләгән зоналар һаман да бар әле.

Район җитәкчеләренең база станцияләре урнаштыру өчен җир бүлеп бирү мәсьәләләрен хәл итүдә булышлык күрсәтүе сорала. Социаль әһәмияткә ия объектларда төбәк инфраструктура элемтә операторы инвестицияләрен җәлеп итәргә кирәк.

Хөрмәтле хезмәттәшләр!

Агросәнәгать комплексы республика үсешенең иң әһәмиятле тармакларыннан берсе булып тора.

Тулай төбәк продуктының 11 проценты азык-төлек сәнәгате белән берлектә агросәнәгать комплексына туры килә.

Бүген Татарстанда дистәләгән социаль программа эшли.

Аларның күбесе авылга ярдәм күрсәтүгә һәм авыл кешеләре өчен тиешле шартлар булдыруга юнәлтелгән.

Елдан-ел әлеге чараларның саны арта бара, яңа юнәлешләр ачыла. Беренче чиратта, эшмәкәрлекне үстерү өлкәсендә зур эш алып барыла.

Республикада хуҗалык итүнең кече формаларына ярдәм күрсәтү буенча зур эш уздырыла һәм ул үзенең уңай нәтиҗәләрен бирә.

Узган елда республикадагы тулаем авыл хуҗалыгы продуктлары күләменең яртысыннан артыгы алар тарафыннан җитештерелде.

Фермер хуҗалыклары күрсәткечләре тотрыклы рәвештә үсә. Узган елда тулай продукт күләме буенча аларда үсеш 16 процентны тәшкил итте.

Республика Парламенты Рәисе Фәрит Хәйрулла улы Мөхәммәтшин һәм авыл хуҗалыгы министры Марат Готыф улы Әхмәтов тарафыннан авылларда эшлекле активлыкны үстерү буенча алып барылган уңай эшчәнлекне аерып билгеләп үтәргә кирәк.

Агросәнәгать комплексы өлкәсендә кече секторны үстерү күп очракта продуктларны эшкәртү һәм аларны сату мәсьәләләрен хәл итүгә бәйле.

Республикада Россия күләмендә иң зур агросәнәгать паркы эшләп килә, аның эшкәртү цехлары да бар. Бу елдан авыл җирлекләрендә – Кукмара, Чүпрәле, Саба, Бөгелмә, Әлмәт, Зәй районнарында, алга таба республикабызның башка районнарында да агросәнәгать парклары төзү программасы эшли башлаячак.

Авыл хуҗалыгы продуктларын эшкәртү һәм сату мәсьәләләрен хәл итүдә авылларда кулланучылар кооперацияләрен үстерү зур ярдәм булачак.

Республикада 46 кооператив булдырылды. Безнең алда аларның санын икеләтә арттыру бурычы тора.

Кооперативлар һәр районда булырга тиеш.

Эшкуарлар һәм товар китерүчеләр белән продуктларны сертификатлаштыру, аларның сату-алу сессияләрендә катнашу мәсьәләләре буенча комплекслы эшне дәвам итәргә кирәк. Төбәк товар җитештерүчеләре продуктларын федераль һәм

халыкара сәүдә челтәрләренә сатуга чыгару, алга таба аларга тышкы базарга юл ачачак.

Агросәнәгать комплексы өлкәсендә продуктларның конкурентлыкка сәләтле булуларын тәэмин итү өчен дөнья практикасының иң яхшы үрнәкләрен һәм югары технологияләрне актив рәвештә кулланышка кертергә кирәк.

Хөрмәтле депутатлар!

Тиз үзгәрүче дөнья хезмәт базарына да яңа таләпләр куя.

Иң беренче чиратта, сүз хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру турында бара. Барлык тармакларда да, аеруча бюджет өлкәсендә сакчыл җитештерү принципларын һәм инструментларын куллану зарур.

Хезмәт җитештерүчәнлеген үстерү – хезмәт хакын арттыруның төп чыганагы.

Заманча бизнесның яңа тенденциясе булып «офистан тыш эшләү» тора. Читтән торып эшләүгә күчү моңа кадәр хезмәт базарында катнаша алмаучыларга, мәсәлән, бала карау буенча ялда булган яшь әниләр яисә сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле кешеләргә эшкә урнашу мөмкинлеге бирә.

Хөкүмәттән әлеге практиканы өйрәнүне һәм тиешле тәкъдимнәр әзерләү эшен уздыруны сорыйм.

Теләсә кайсы үзгәрешнең үзәгендә кеше тора.

Өзлексез белем бирүнең нәтиҗәле эшләүче бердәй системасын төзү кирәк, ул, кызганычка күрә, бүгенге көндә камил түгел.

Нәкъ менә мәгърифәт дөньяны үзгәртергә сәләтле.

Сабыйларыбызның киләчәктә уңышлы үсешенә нигез булачак белем һәм күнекмәләр нәкъ менә кечкенәдән үк бирелә.

Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре шуны истә тотып, аеруча телләр өйрәтүгә зур игътибар биреп эшләргә тиешле.

Берничә тел белү – конкурентлыкта өстенлек ул.

Мәктәпләребездә белем бирүнең сыйфатына аерым игътибар юнәлтү таләп ителә. Ул мәгариф өлкәсе хезмәткәрләренең оештыруда куйган тырышлыгына түгел, бәлки мәктәп тәмамлаган укучыга ихтыяҗ дәрәҗәсенә, аның киләчәктә белгеч буларак ирешкән уңышларына карап бәяләнергә тиеш.

Мәгариф системасында эш сыйфатын яхшыртуның нигезен педагогның һөнәри осталыгы, аның белем һәм методика өлкәсендә заман таләпләренә туры килергә омтылуы, укучыларның сәләтләрен һәм мөмкинлекләрен күрә һәм үстерә белүе тәшкил итәргә тиеш.

Бу – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы җаваплылыгындагы даирә.

Укытучыларның квалификациясен күтәрү формаларын камилләштерү, аларның белем дәрәҗәсен бәяләүнең яңа объектив методларын куллану зарур.

Район башлыкларына һәр мәктәптә белем бирүнең сыйфатын мониторинглау эшен башларга кирәк.

Шул ук вакытта әлеге мәгълүмат барлык ана-аналар өчен ачык һәм аңлаешлы булырга тиеш.

Мәгариф системасында ресурс үзәкләре мөһим роль уйный. Бүгенге көндә аларның саны 25 кә җитте. Аларның бурычы – төп предприятиеләр өчен корпоратив уку үзәкләренә әверелү.

Хөкүмәтебезгә әйдәүче предприятиеләр белән берлектә сәнәгать үсешен кадрлар белән тәэмин итүнең төбәк стандартын гамәлгә кертүне, шулай ук һөнәри белем бирү сыйфатына бәя бирүдә бәйсез экспертлар хезмәтен куллану системасын формалаштыруны дәвам итәргә кирәк.

Халыкара стандартлар нигезендә укытучыларны алгарышлы рәвештә яңадан әзерләүне һәм аларның квалификацияләрен күтәрүне, шулай ук эш бирүчеләр катнашында аларны укыту һәм аттестацияләүне тәэмин итәргә кирәк.

Безнең WorldSkills хәрәкәтендә катнашуыбыз һәм Казан шәһәрендә дөнья беренчелеген уздыруга әзерлек һөнәри белем бирүне үстерүнең мөһим факторы булып тора.

Безгә дөньядагы иң яхшы гамәли тәҗрибәләрне үзләштерү һәм аларны республикабызда гамәлгә кертү өчен уникаль мөмкинлек бирелде. Безнең бурыч – аларны дөрес куллану.

Татарстанда махсуслаштырылган лицейлар һәм гимназияләр челтәре үстерелә. Бездә аларның саны 15кә җитте.

Балалар технопарклары эшчәнлеге уңай бәяләнде. Чаллы, Түбән Кама һәм Әлмәт шәһәрләрендә – Кванториум.

Әлеге үзәкләрнең үзара килешенгән эше нәтиҗәсендә без киләчәктә белем дәрәҗәсе югары белгечләр, галимнәр, уйлап табучылар һәм инженерлар буынын формалаштырачакбыз.

Һөнәри юнәлеш сайлау эшен камилләштерүдә сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле кешеләргә, ата-ана ярдәменнән мәхрүм ятим балаларга, шулай ук авыр социаль шартларда калган яшүсмерләргә аерым игътибар бирергә кирәк.

Югары уку йортлары эшчәнлегенә аерым тукталып үтәсем килә. Хәзерге заман шартларында аларның бурычы булып уку-укыту процессы гына түгел, ә белемнәрне капиталлаштыру да тора.

Югары уку йортлары бер үк вакытта предприятиеләр өчен технологияләр һәм киләчәк һөнәрләре өчен кадрлар әзерләү үзәкләре булырга тиеш.

Үзебездә эшләп килүче милли тикшеренү университетларының игътибарын шуңа юнәлтәсем килә: алар үзләренең нәкъ менә икътисадның төп тармакларына ярдәм йөзеннән оештырылган булуларын онытмасыннар иде.

Без проектлаштыру өлкәсендә новатор, алдынгы проектлар инициаторы булырдай, даими рәвештә замана таләпләренә җавап бирердәй яңа һәм нәтиҗәле алымнар эзләячәк Яңа буын университетлары форматы булдырырга тиешбез.

Алдынгы практикаларны кулланып, эчке корпоратив идарә технологияләре, уку-укыту һәм стажировкалар узу мәйданчыклары, проект офислары булдырырга, онлайн-укыту технологияләрен үстерергә кирәк.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына югары уку йортлары белән берлектә киләсе елның азагына кадәр әлеге бурычларны хәл итү буенча юл картасы эшләүне йөклим.

Хөкүмәткә КФУ, Иннополис университеты базасында әйдәүче предприятиеләр катнашында Инновацияле фәнни-технология үзәкләре булдыру мәсьәләсен хәл итәргә кирәк.

Бу фәнни эшләнмәләрне коммерцияләштерү өчен яхшы җирлек булып тора.

Бүгенге көнгә кадәр предприятиеләр, югары уку йортлары һәм тармак министрлыкларының республика Фәннәр академиясе белән нәтиҗәле үзара эшчәнлек алып бару механизмы эшләнмәгән. Фәннәр академиясен әлегә фәнни тикшеренүләр һәм гамәли характердагы эшләнмәләр туплану үзәге дип әйтеп булмый.

Башкарылган хезмәтләрнең төп күләменә ихтыяҗ бик аз.

Академиянең мөмкинлекләре гаять зур. Аннан нәтиҗәле файдаланырга кирәк.

Хөкүмәтебезгә киләсе елга һәм аннан соңгы ике елга Фәннәр академиясе өчен гамәли тикшеренүләр планын, аны Академиянең дәүләт бурычы исемлегенә кертеп, формалаштыруны контрольгә алуны тапшырам.

Мәгариф системасының өстенлекле һәм аеруча катлаулы бурычы – балаларга тәрбия бирү мәсьәләсе. Белем бирү һәм тәрбиянең бер-берсе белән тыгыз бәйләнеше турында сөйләп кенә калмыйча, моны гамәлдә тормышка ашырырга кирәк.

Әлеге эш чаралар һәм акцияләр уздыруга гына кайтып калмасын. Һәрбер укытучы һәм сыйныф җитәкчесе тәрбияче булырга тиеш.

Үзара ышаныч һәм хөрмәткә нигезләнгән тәртип, яшь татарстанлылар аңына оста итеп, бала күңеленә каты бәрелмичә традицион рухи кыйммәтләр төшенчәсен, сәламәт яшәү рәвешенә һәм иҗади эшчәнлеккә омтылыш сеңдерү – шәхес, зур һәм көчле ил гражданы  формалаштыруга җирлек булып тора.

Һичшиксез, тәрбия процессында төп роль гаиләгә бирелә. Нәкъ менә монда гореф-гадәтләребез буыннан буынга тапшырыла килә, Ватаныбызга мәхәббәт һәм хөрмәт хисләре тәрбияләнә.

Гаиләләрнең икътисадый һәм социаль-мәдәни хәлен яхшырту, шулай ук бала табуга, күп бала табуга ата-аналарны кызыксындыру эшен дәвам итү гаять мөһим.

Гаилә – кеше тормышында нык терәк, җәмгыятьнең һәм дәүләтнең төп нигезе.

Ул безне шәхес итә, яратырга һәм кайгыртырга өйрәтә, гореф-гадәтләр, мәдәният һәм тел сагында тора.

Һәр гаиләнең үз тарихы, үзенә генә хас карашлары, йолалары бар.  Әлеге кыйммәтләрне саклау бик мөһим, чөнки бу – республиканың иминлеге һәм якты киләчәге нигезе.

Хөрмәтле хезмәттәшләр!

Республикада сәламәтлек саклау тармагына һәрчак зур игътибар бирелә.

Медицина учреждениеләрен төзү, төзекләндерү һәм җиһазлау, югары технологияле медицина ярдәмен камилләштерү буенча планлаштырылган чараларны гамәлгә ашыру күрсәтелгән медицина хезмәтләренең сыйфатын яхшыртуга ярдәм итә.

Республикада уртача гомер озынлыгы 73,5 елдан артып китте.

Шул ук вакытта, поликлиникаларда махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итәсе бар әле.

Аны комплекслы рәвештә – цифрлы, оештыру һәм кадрлар технологияләрен бер үк вакытта файдаланып хәл итү зарур.

Республикада беренчел звеноны үстерүгә аеруча зур басым ясала, авыруларның 80 проценты нәкъ менә шушы оешмаларга мөрәҗәгать итә һәм дәвалана.

Быел өр-яңа программа эшли башлады. Ике ел эчендә Татарстанның барлык поликлиникаларны капиталь төзекләндерү, аларны нормаларга туры китерү һәм заманча җиһазлар белән тәэмин итү эшен башлау планлаштырыла.

Бу – барлыгы 197 объект!

Әлеге максатларга республика бюджетыннан 7,5 миллиард сум акча бүлеп бирелде.

Матди-техник яктан тәэмин итү белән берлектә, поликлиникаларда пациентлар белән эшләүгә юнәлтелгән заманча технологияләрне гамәлгә кертү мөһим бурыч булып тора, шуларның берсе – «Дустанә поликлиника – Татарстан стандарты».

Әлеге проект республикабызның зур шәһәрләрендә уңышлы рәвештә сынау узды, халык һәм медицина хезмәткәрләре тарафыннан хупланды.

Бердәм кыйммәтләр нигезендә заманча аралашу технологияләрен гамәлгә кертүгә республика Сәламәтлек саклау министрлыгының Корпоратив университеты ярдәм итәргә тиеш.

Әлеге проектны үстерү эшен дәвам итәргә кирәк.

Дәүләтнеке һәм дәүләтнеке булмаган сәламәтлек саклау системасын берләштерү өлкәсендә мөһим бурычларны хәл итәргә кирәк булачак.

Медицина хезмәте күрсәтүнең дәвамчанлыгына ирешергә, авыруларның бердәм мәгълүмат базасын формалаштырырга, диагноз кую буенча тикшеренүләрнең нәтиҗәләрен саклауны оештырырга һәм аларны кирәк вакытта файдалану мөмкинлеген булдырырга тиешбез.

Хезмәткә сәләтле халыкның сәламәтлегенә аеруча игътибар бирергә кирәк.

Сәламәтлек саклауның нәтиҗәле юнәлешләренең берсе – предприятиеләр хисабыннан тулысынча медицина тикшеренүе узуны оештыру һәм һөнәри эшчәнлеге нәтиҗәсендә куркыныч авырулы булган хезмәткәрләргә онкоскрининглар уздыру тора.

Хөкүмәткә, депутатлар корпусына, республиканың предприятиеләр ассоциациясенә һәм һөнәр берлекләренә мөрәҗәгать итеп, әлеге бурычны тормышка ашыру буенча килешенгән карарлар кабул итәргә.

Республикада спорт инфраструктурасын актив үстерү, ГТО системасын гамәлгә кертү, спорт чараларын еш уздыру сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруда уңай этәргеч бирә.

Татарстанда физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүчеләрнең саны елдан-ел арта бара. 2016 елда ул 41,5 % тәшкил итте.

Универсаль спорт мәйданчыклары булдыру программасы бу уңайдан бик зур ярдәм булды.

4 ел эчендә 671 шундый мәйданчык төзелде. Быел тулаем республика буенча тагын 139 объект төзелер дип планлаштырыла, болар – спорт мәйданчыклары, хоккей тартмалары, блоклы модульле чаңгы базалары, шулай ук 8 ябык бассейн.

Массакүләм физик культура хәрәкәтен алга таба да үстерү зарур.

Спорт өлкәсендә төп бурычларның берсе – спорт казанышларының нәтиҗәлелеген һәм татарстан спортчыларының конкурентлыкка сәләтен арттыру тора.

Бу – турыдан-туры Спорт министрлыгы бурычы!

Сәләтле яшь спортчылар һәм перспективалы тренерлар белән индивидуаль эш алып баруны тагын да көчәйтергә, шулай ук республикага югары дәрәҗәдәге белгечләрне җәлеп итү өчен барлык кирәкле шартлар тудырырга кирәк.

Социаль яклау өлкәсендә мөһим юнәлешләр булып олы яшьтәге гражданнарга социаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатын яхшырту һәм әлеге хезмәтләрдән һәркемнең файдалануын тәэмин итү, бу гражданнарны укыту, инвалидларны эшкә урнаштыру, ятим балалар турында кайгырту, сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балаларның җәмгыять тормышының барлык өлкәләрендә катнашуы өчен шартлар булдыру тора.

Шунысы гаять сөенечле, республикада меценатлык һәм хәйриячелек эше көннән-көн зур популярлык казана.

Битараф булмаган меңнәрчә татарстанлы төрле акцияләрдә катнаша, хәленнән килгәнчә мохтаҗ кешеләргә ярдәм итә.

«Игелекле Казан» проекты уңышлы эшли.

Әлеге тәҗрибәне республикабызның башка шәһәр, районнарына да тарату матур нәтиҗәләр бирер иде.

Хөрмәтле татарстанлылар!

Вакыт бик тиз бара.

Һәр көнне дөньяда тормышыбызны тамырдан үзгәртергә сәләтле яңа технологияләр барлыкка килә, яңа идеяләр туа тора.

Боларның барысын да кешеләр башкара.

Без зур мөмкинлекләр чорында яшибез. Республикабыз да зирәк акыллы кешеләргә бай.

Хыялланыгыз, иҗат итегез, масштаблы планнар корыгыз һәм һәрчак белем туплауны, өйрәнүне дәвам итегез. Бары тик шул очракта гына алга хәрәкәт тукталмас!

Иртәгесе уңышның орлыклары – бүгенге туфракта үсә.

Куәтле Татарстанның һәм көчле Россиянең киләчәге безнең кулларда!

Бу эштә һәммәбезгә дә зур уңышлар телим!

Рәхмәт сезгә! ».